**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3065**
**17.06.2022**

Озак сроклы чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет фаразын эшләү һәм раслау кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 170.1 статьясындагы 4 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Озак сроклы чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет фаразын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 17 июнендәге
3065 номерлы карарына
кушымта

Озак сроклы чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
бюджет фаразын эшләү һәм раслау
кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр озак сроклы чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет фаразын (алга таба – бюджет фаразы) эшләү һәм раслау тәртибен, срокларын һәм шартларын, шулай ук составына һәм эчтәлегенә карата таләпләрне билгели.

2. Бюджет фаразын эшләүне (бюджет фаразын үзгәртүне) Башкарма комитетының финанс идарәсе гамәлгә ашыра.

3. Бюджет фаразы тиешле чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты юлламасы нигезендә, һәр өч ел саен, алты һәм аннан күбрәк елга әзерләнә.

4. Бюджет фаразы үз эченә түбәндәге позицияләрне ала:

1) шәһәр бюджеты үтәлешенең төп нәтиҗәләре, агымдагы чорда бюджет фаразын формалаштыру шартлары;

2) озак сроклы фараз вариантлары параметрларын тасвирлау һәм, бюджет фаразы максатлары өчен нигез буларак, озак сроклы фараз вариантын сайлауны нигезләү;

3) озак сроклы чорда бурыч, салым һәм бюджет сәясәтен формалаштыруга төп алымнар;

4) сайланган сценарийны исәпкә алып, шәһәр бюджетының төп характеристикалары фаразы, шул исәптән, әлеге Кагыйдәләргә кушымта нигезендә, аларның гамәлдә булу чорына муниципаль программаларны тормышка ашыруны финанс белән тәэмин итү күрсәткечләре.

5. Бюджет фаразын формалаштыру (бюджет фаразын үзгәртү) максатларында Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, агымдагы елның 22 июленә кадәр срокта, Башкарма комитетның финанс идарәсенә тапшыра:

1) агымдагы финанс елының узган чорында шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенә якынча йомгаклар һәм агымдагы финанс елында шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенең көтелгән нәтиҗәләре;

2) шәһәрнең социаль-икътисадый үсеш фаразы.

6. Бюджет фаразы (бюджет фаразын үзгәртү), Шәһәр Советының чираттагы елга һәм план чорына шәһәр бюджеты турындагы карары рәсми

бастырып чыгарылган көннән башлап ике айдан артмаган срокта, Башкарма комитет карары белән раслана.

7. Бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты) (муниципаль программаларны финанс белән тәэмин итү күрсәткечләреннән тыш) шәһәр бюджеты турындагы карар проекты белән бергә Шәһәр Советына тапшырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Озак сроклы чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет фаразын эшләү һәм раслау кагыйдәләренә кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының төп характеристикалары фаразы

(мең сум)

| Төп характеристикалар исеме | Хисап елы | Агымдагы ел | Чираттагы ел (n) | Планлы чорның беренче елы (n + 1) | Планлы чорның икенче елы (n + 2) | (n + 3) | (n + 4) | (n + 5) | (n + 6) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| КЕРЕМНӘР, шул исәптән: | | | | | | | | | |
| Салым кучерүләре | | | | | | | | | |
| һәм салым булмаган күчерүләр | | | | | | | | | |
| Кире кайтарылмый торган күчерүләр | | | | | | | | | |
| ЧЫГЫМНАР, шул исәптән: | | | | | | | | | |
| Муниципаль программалар | | | | | | | | | |
| Дефицит/профицит | | | | | | | | | |